РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» июнь 2018ел. № 159/БК/к

2018 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы чиге

- 1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен-1 233 474,00 сум.;
- 1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен-1 569 876,00 сум.;
- 1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен-2 018 412,00 сум.;
- 1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен-2 691 216,00 сум – ;
- 1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 3 364 020,00 сум.;
- 1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен-4 036 824,00 сум.;
- 1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 709 628,00 сум.;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

- 1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 12 378,23 сум.;
- 1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 7 877,06 сум.;
- 1.2.3. өч кешедән һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 6 751,76 сум.

1.3. Торак урыннарына мохтаҗларны исәпкә куйганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне кулланырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Р.Р. Камартдинов